КАРАР

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге Биккол авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«19» ноябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2019 елның 19 ноябрендә узган: «Сез, 2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге Биккол авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.

- Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 291 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 185 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 1821кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 5 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге Биккол авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.

- Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлегенең Биккол авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыены рәисе: Р.Х.Әхмәтшина

Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Әхмәтшина